ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДАНАУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422951, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
д.Данауровка, ул.Центральная, 20 «А»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАНАУРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422951, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Данауровка авылы,
Центральная урамы, 20 «А»

e-mail: Dnr.Ctp@tatar.ru тел. (84342) 5-71-38

Постановление Карар

2020 елның 16 июле №7

Сайлау алды басма агитация материалларын
урнаштыру өчен махсус урыннар турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга**.**
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, белдерүләр стендларында һәм такталарында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Данауровка

авыл җирлеге башлыгы _____________ В.К.Сәдретдинова

Данауровка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 16 июлендәге
7 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын адресы | Урнаштыру урыны исеме |
|---|---|---|
| 2792 | ТР,Чистай районы, Данауровка авылы, Центральная ур. | игълан тактасы |
| 2792 | ТР,Чистай районы, Галактионово авылы, Новосельская ур. | игълан тактасы |